**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№1902**
**19.03.2021**

Башкарма комитетның «2021-2023 елларга Яр Чаллы шәһәренең территориаль иҗтимагый үзидарәсен үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2020 елның 30 октябрендәге 5734 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Яр Чаллы шәһәре территориаль иҗтимагый үзидарәсенең тотрыклы эшләве һәм үсеше өчен шартлар тудыру максатында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставы, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2021-2023 елларга Яр Чаллы шәһәренең территориаль иҗтимагый үзидарәсен үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2020 елның 30 октябрендәге 5734 номерлы карарының 2 пунктына, аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә «2021-2023 елларга Яр Чаллы шәһәренең территориаль иҗтимагый үзидарәсен үстерү» муниципаль программасы чараларын финанслауны шәһәр бюджеты акчалары хисабына «Төзекләндерү» 05.03 бүлеге (бүлекчәсе) буенча 15 450,00 мең сум күләмендә, «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре» 01.13 бүлеге (бүлекчәсе) буенча 1 050,00 мең сум күләмендә тәэмин итәргә: 2021 ел – 5 500,00 мең сум, 2022 ел – 5 500,00 мең сум, 2023 ел – 5 500,00 мең сум.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка, Башкарма комитетның районнар хакимияте Башлыклары А.И. Кисловка, И.Н. Галимовка, В.Х. Харисовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов